ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО
ПОСЕЛЕНИЯ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.17,
с.Акбаш, 423958

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
Мәктәп урамы, 17йорт,
Акбаш авылы, 423958

Тел.:(85593) 4-14-34, факс:4-14-34, e-mail: Akbash.Utz@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

№6 «21» февраль 2025 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 15 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару кагыйдәләрен раслау турында»гы 16 санлы карарының үз көчен югалтуын тану хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 1998 елның 24 июнендәге «Җитештерү һәм куллану калдыклары турында»гы 89-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлек Уставына таянып, норматив хокукый актларны Россия Федерациясе һәм Татарстан Республикасы законнарына туры китерү максатларында, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге башкарма комитеты к а р а р б и р ә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Башкарма комитетының 2020 елның 15 сентябрендәге «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының «Акбаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге территориясендә каты коммуналь калдыклар туплау урыннарын (мәйданчыкларын) төзекләндерү һәм аларның реестрын алып бару Кагыйдәләрен раслау турында»гы 16 санлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми бастырып чыгару юлы белән рәсми рәвештә халыкка җиткерергә (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә

органнарының «Рәсми Татарстан» бердәм порталын урнаштырырга. «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге веб-адресы буенча урнаштырырга: http://jutaza.tatarstan.ru/.

3. Әлеге карар рәсми игълан ителгән көннән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р. Сәхибуллина